# Яшьлек

Минзәлә шәһәре гимназиясе
Киләчәкнең башы - бүгенгедә
1998

*Апрель, 2017 ел*



## Атна шәхесе - Айнур!



## Көлке көне



## Күңелләрдә мәңге Тукай!

# Атна шәхесе - Шәрифуллин Айнур!

Атна шәхесе - Шәрифуллин Айнур!



Бу айның шәхесе– Айнур! Ул бик елмаючан, шаян һәм позитив егет! 💪 😳 18 нче апрель көнне узган КВН бәйгесендә ул үзен бары тик уңай яклардан гына күрсәтте. Гимназиянең “Тюбетейка ” командасы 1 урын яулады. Без алар белән бик горурланабыз!

**Туган көне : 14.05.00**
**Ф.И.О.: Шәрифуллин Айнур Альфир улы**
**Яраткан фильмы: “Великий Гэтсби”**
**Яраткан ризыгы: барысын да яратам**

- **Сәлам, Айнур!**

-Сәлам, Айзилә.

- **Әгәр дә “вакыт машинасы”на утырып, үткәнгә кайтып булса, син нәрсә үзгәртер идең?**

- Бернәрсә дә үзгәртмәс идем.

- **Тормышыңда синең өчен ни мөһим?**

- Әлбәттә, гаиләм.





- **Тормышыңда “башсызлык” дип әйтерлек гамәл кылганың бармы?**

- Минем күп гамәлләрем шулай, ахрысы (көлә).

- **Син үзеңне уңышлы кеше дип саныйсыңмы?**

- Әлбәттә!

- **“Эх, туган көн, туган көн...” дигән җырны дәвам ит.**

- Акча бирә торган көн... (көлә)



- **Нинди 3 әйбердән куркасың?**

- Бернәрсәдән дә курыкмыйм.

- **Кечкенә чагында нинди һөнәр сайлыйсың килгән иде һәм хәзерге вакытта син ул һөнәрне сайларга әзерме?**

- Мин кечкенә чагымда берни эшләми диванда яту һәм моның өчен акча түләүләрен тели идем, хәзер дә шулай ук (көлә).

- **Җәйгә планнарың нинди?**

- О-о-о,бернинди дә.

# Күнелләрдә мәңге Тукай!



Менә тагын ямьле апрель җитте! Без бу айда бөек Габдулла Тукай белән татар телебезне зурлыйбыз, күңелләрдә милли горурлык хисләрен кузгатабыз. Ата-бабаларыбыздан калган мирасыбыз - туган телебезне - һәркем белергә тиеш, бу - һәрберебезнең изге бурычы.Тел безне тарихыбыз, нәселебез белән бәйли, безгә рухи ләззәт, көч бирә, артыбызда ата-бабаларызның рухлары булганда, үзебезне нык, ышанычлы итеп хис итәбез. Габдулла Тукайның язмышы хакында укыганда, күңелем тула, күзләрем яшьләнә. Кыска гына гомерендә халкы өчен күпме мирас калдырган бөек милләттәшебез, милләтебезнең бизәге!

Ә халкыбызның горурлыгы, куанычы булып торган язучы-шагыйрьләр: Һади Такташ, Гадел Кутуй, Аяз Гыйләҗев, Абдулла Алиш һәм башкаларның әсәрләрен ана телендә укый алу үзе бер бәхет, дип саныйм.Талантлы, уңган татар шәхесләренең әсәрләрен укыганда, мин үземнең шушы милләттән булуыма, шушы әсәрләрне тулысында аңлавыма зур горурлык һәм бәхет кичерәм: мин дә бит шушы үзенчәлекле, кабатланмас культураның, халыкның бер өлеше, дип куанам.

26 апрель көнендә Мөслимдә Габдулла Тукайның 131 еллыгына багышланган квест-уены булып узды! Бу бәйгедә Минзәлә данын яклап, гимназиянең 8-нче һәм 10-нчы сыйныф укучылары катнашты. Һәм нәтиҗәдә Минзәлә командасы 2-нче урынга лаек булды!Аның белән генә аерылып калмадылар, безнең гимназиядә дә Габдулла Тукайның иҗатына багышланган квест-уен уздырдылар! 7,8,10 класс укучылары көч сынаштылар, нәтиҗәдә 8 класс җиңү яулады.



Кайбер укучыларның бу бәйге турында уй-фикерләрен сорап китик әле :



Галимҗанова Лилия, 7 нче сыйныф укучысы:

- Без бу бәйгегә бик җитди карадык: Габдулла Тукайның иҗаты һәм тормыш юлын яхшылап өйрәндек.

Авзалтдинова Гүзәл, 8 сыйныф укучысы:

- Миңа бәйге бик ошады. Аеруча бу бәйгенең оештыручыларына - татар теле һәм әдәбият укытучыларына - рәхмәтемне белдерәм. Шундый кызыклы бәйгеләр ешрак булсын иде.”



*Сәхәбетдинова Регина*

# Космонавт - сирәк һөнәр



*Ул, Галәм гизеп,*
*Исән-сау төште!*
*Ни бар соң җирдә*
*Кешедән көчле?!*

Космосның батыр йөрәкле каһарманы, илебезнең данлыклы улы. Кыска гына вакыт эчендә айга менә, Кояш системасының барлык планеталарын тикшерә, әмма беренче очыш авыр һәм куркыныч була.
1961 елның 12 апреле. Бу көн кешелек тарихына мәңгелеккә кереп калды. Язгы иртәдә көчле ракета җир йөзенең беренче космонавты – Советлар Союзы гражданины Юрий Гагарин белән тарихта беренче “Восток” космик кораблен бортта орбитага чыгарды!

Беренче космик очыш **108** минут дәвам итте. Безнең көннәрдә орбиталь космик станцияләрдә күп экспедицияләр кылган вакытта, ул кыска булып тоела. Әмма бу минутларның һәрберсе билгесез нәрсәләрнең ачышы булып тора.
Юрий Гагаринның очышы кешенең яшәргә мөмкинлеген һәм галәмдә эшли алганын исбат итте

Космонавт һөнәре кешегә бик югары таләпләр куя. Космонавт иң элек бик яхшы сәламәтлеккә ия булырга тиеш. Аңа гади булмаган шартларда эшләргә туры килә: орбитага чыгарганда һәм бигрәк тә җиргә кире кайтканда аңа шактый күп эш йөкләнә. Космонавт – сирәк һөнәр. Космонавт батыр һәм кыю йөрәкле кеше булырга, теләсә нинди ситуациядә зирәк, теләсә нинди шартларда тиз генә дөрес карар кабул итәргә тиеш. Шулай ук космик техниканы бик яхшы белергә һәм кимчелексез йөртергә тиеш.



“Гагарин беркайчан да үзен әллә-кемгә куймаган,һәрвакыт гади кешеләр арасында булган. Әйе,гади,батыр һәм кыю егет булган ул Гагарин”-дип, язган очучы-космонавт К. П. Феоктистов.



*Дәвамы киләсе биттә…*

# Башыңны югары күтәр!



Космонавтика көнендә социаль челтәрләрдә **“Башыңны югары күтәр”** флешмобы уздырылды.

Акцияне уздыру уе Санкт-Петербургта “Дөреслек һәм гаделлек” (“Правда и справедливость”) Бөтенроссия халык фронты медиафорумында барлыкка килде. Флешмобта бик күп кешеләр теләп катнаштылар.

Социаль челтәр кулланучылары, башларын югары күтәреп күк йөзенә карап, үз-үзләрен фотога төшерергә (“селфи” ясарга) һәм #поднимиголову хештегын куеп, үз аккаунтларында әлеге фотоны чыгарырга тиеш иделәр.





Фотоларны челтәргә чыгару Мәскәү вакыты белән 09.07 сәгатьтә башланып китте,чөнки кайчандыр Юрий Гагарин космоска менгән “Восток-1” космик корабле нәкъ шул сәгатьтә старт алган.

Әлбәттә, бу бөек дата безнең районыбызны һәм мәктәбебезне дә урап узмады, бик күп төрле чаралар, сыйныф сәгатьләре һәм кызыклы дәресләр үткәрелде. Нәтиҗәләр дә мактанырлык! Мәсәлән, Космонавтика көненә багышланган квест-уенында барлык мәктәпләр арасында беренчелекне гимназия яулады! Афәрин!

Низамова Сөмбел

# Көлке көне



1 нче апрель - көлке, эчкерсез алдашулар көне. Көлке көне барлык дөньяларны берләштерә. Бу - элеккеге заманнардан килгән һәм бөтен илләр үткәрә торган бәйрәм. Милли гореф-гадәтләргә карамыйча, һәрбер кешедә төрле кызыклы хәлләргә, мәзәкләргә ярату яши. Көлү - ул бәхет. Һәркемнең дә бәхетле буласы килә.

Әлеге бәйрәмнең барлыкка килүенә карата төрле версияләр яши.



Берәүләр аны апрельдә үткәрелә торган борынгы яз бәйрәменә бәйләп карый. Ә икенчеләр дусларны кызык хәлләргә кую гадәте урта гасырларда туган дип саный.

Ничек кенә булмасын, көлке көне кәефне күтәрә, күңелгә рәхәтлек бирә, борчу-сагышларны азга гына булса да оныттыра 😃

Хәбирова Наилә

# Туган көн- гомер бәйрәме...



**Укытучылар:**
**Рәйханә Кәрамовна (01.04)**
**Нина Николаевна (07.04)**
**Гүзәл Назимовна (15.04)**
**Альбина Музагитовна (20.04)**
**Гүзәл Фердинандовна (24.04)**
**Ленар Нурович (8.03)**
**Шәүкәт Рәшитович (14.03)**
**Марат Фәезович (18.03)**
**2 нче сыйныф:**
**Зыятдинов Илфар (14.04)**
**3 нче сыйныф:**
**Вәлиева Динара (15.04)**
**4 нче сыйныф:**
**Сираев Эмиль (4.04)**
**5 нче сыйныф:**
**Мулләхмәтова Айзилә (12.04)**
**Хисамова Лилиана (5.04)**
**Хәбирова Ләйлә (16.04)**
**Яковлева Алсу (24.04)**
**Шәрипов Денис (25.04)**
**6 нчы сыйныф:**
**Мөбарәкҗанов Рифат (12.05)**
**7 нче сыйныф:**
**Бигимова Элина (15.04)**
**Ибраһимова Нәзилә (15.04)**
**8 нче сыйныф:**
**Шәрифуллина Рүзилә (11.04)**
**Әкбәров Рәсүл (02.04)**
**9 нчы сыйныф:**
**Әхмәтшина Ләйсән (21.04)**
**Шәрипова Чулпан (27.04)**
**10 нчы сыйныф:**
**Батталов Нияз (24.04)**
**11 нче сыйныф:**
**Әкбәрова Лилия (25.04)**





**Баш мөхәррир** —Низамова Сөмбел
**Әдәби консультантлар-** Җәмилова Айзиля, Шәрифуллина Рүзилә
**Бүлек мөхәррирләре** - Хәбирова Наилә, Сәхәбетдинова Регина
**Проект җитәкчеләре** — татар теле һәм әдәбияты укытучылары Ильина Миләүшә Әхтәм кызы, Заһриева Гөлнара Рөстәм кызы.

423700, ТР, Минзәлә шәһәре,
Чаллы тракты, 1А,
тел./факс (885555)3-51-71,
www.gimnazia-menz.edusite.ru
e-mail: sch1104_tg@mail.ru
Instagram: @gimnaziya__official
http://vk.com/id324010745